РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

**№ 30/1** **2018 елның 02 феврале**

***Решение*** ***Карар***

«Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр кертү турында»
карар проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 85 - 87 статьялары нигезендә, Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Советы карары проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшләүне дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү буенча түбәндәге составта тәкъдимнәр кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эш төркеме төзергә:

Хаматов Рөстәм Гарип улы - Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары, комиссия рәисе;

Комиссия әгъзалары:

Иванов Константин Валентинович - Чистай муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе;

Заглядова Ольга Валентиновна - Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты эшләр идарәчесе;

Ильин Эдуард Борисович - Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлеге башлыгы;

Осипов Геннадий Николаевич - Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Садриева Илсөяр Шамил кызы - Чистай муниципаль районы советы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү бүлеге башлыгы;

Җәләлова Динара Наил кызы - Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;

Абзалова Лилия Нургаяз кызы - Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы.

3. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Советы карары проектына һәм гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен (2 нче кушымта) расларга.

4. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибен (3 нче кушымта) расларга.

5. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Советы карары проекты буенча 2018 елның 20 февралендә 10.00 сәгатьтә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты конференц-залында ачык тыңлаулар уздырырга.

6. Чистай муниципаль районы гражданнарының кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясе каравына кертергә, алга таба Чистай муниципаль районы Советы утырышында карарга.

7. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә (Г.Н. Осипов) йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов

Чистай муниципаль районы
Советының 2018 елның
«2» февралендәге 30/1 номерлы
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карары проекты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 85 - 87 статьялары нигезендә, Чистай муниципаль районы Советы карар бирә:

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2014 елның 29 гыйнварындагы 32/1 номерлы карары белән кабул ителгән «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 16 статьяда:

исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«16 статья. Ачык тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулары»;
3 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) Районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;»;
10 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:
«10. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау кагыйдәләре проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә яисә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен үзгәртү мәсьәләләренә, җирдән файдалануның расланган кагыйдәләре булмаганда һәм төзелеш корылмаларын файдалануның башка төрен үзгәртү мәсьәләләренә җәмәгатьчелек фикер алышуы яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе, шәһәр эшчәнлеге турындагы кануннарның шәһәр төзелеше турындагы нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.»;

2. 28 статьяның 1пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау;»;

38 статьяның 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.1. Вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Район башлыгы, Район башлыгыннан отставкага китү турында Татарстан Республикасының югары вазыйфаи затының (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенең) хокукый акты нигезендә йә Район башлыгын отставкага җибәрү турындагы район Советы карары нигезендә әлеге хокукый актка яки суд тәртибендә карарга шикаять бирсә, Район Советы Район башлыгын сайлау турында Район Советы составыннан суд карарына кадәр карар кабул итәргә хокуксыз.»;

3. 42 статьяның 1 пунктындагы 1 пунктчасының 8-11 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләүне тәэмин итә;

- район бюджетын үтәүне, районның социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруны оештыра;

- районның комплексы социаль-икътисадый үсеше планнарының һәм программаларының үтәлеше турында хисаплар әзерләүне тәэмин итә;

- Районның икътисады һәм социаль өлкәсе торышын характерлаучы статистик күрсәткечләр җыюны оештыра һәм күрсәтелгән күрсәткечләрне дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тапшыра;».

Чистай муниципаль районы
Советының 2018 елның
«2» февралендәге 30/1 номерлы
карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен һәм аның турында фикер алышуда гражданнар катнашуын исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәр Чистай муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт, факс буенча: 5-43-70 яисә chistay@tatar.ru электрон почта адресына кушымтада бирелгән үрнәк нигезендә язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:mailto:chistay@tatar.ru

| №№ т/б | Пункты, пунктчасы, статьясы | Карар проекты текстлары | Төзәтмә текстлары | Төзәтмәне исәпкә алып, проект | Төзәтмә авторы (ФИО, адресы, эш/уку урыны, |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | тексты | телефоны |
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә карар проекты басылып чыккан көннән бер ай эчендә 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт, 20 нче каб., яисә почта аша (конвертына “Устав буенча фикер алышу” яисә “ачык тыңлаулар” тамга куеп), шулай ук факс буенча: 5-43-70 яисә электрон почта адресына - chistay@tatar.ru. Гаризалар эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Чистай муниципаль районы Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм килүче тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эш комиссиясенә тапшырыла.

Чистай муниципаль районы
Советының 2018 елның
«2» февралендәге 30/1 номерлы
карарына 3 нче кушымта

«Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе.

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба - ачык тыңлаулар) Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы, әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда Чистай муниципаль районы халкы да катнаша, алар Чистай муниципаль районы Советына язмача гаризалар тапшырган.

3. Ачык тыңлауларда халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка барлык кызыксынучы кешеләр, массакүләм мәгълүмат чаралары катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минуттан башлана.

5. Чистай муниципаль районы башлыгы ачык тыңлауларда рәислек итә яисә аның кушуы буенча башка вазыйфаи зат.

6. Халык алдында тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул анда катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча ачык тыңлаулар секретариаты җитәкче һәм

секретариатның ике әгъзасы составында сайлана.

8. Төп доклад белән Чистай муниципаль районы Советы депутаты, депутат комиссиясе вәкиле чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларда катнашучылар, чыгыш ясау хокукы белән, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 3 минуттан да артык түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүченең рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә кушып бирелә. Ачык тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче кул куя һәм Чистай муниципаль районы Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә билгеләнгән тәртиптә басылып чыгарга тиеш һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

18. Ачык тыңлаулар үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Чистай муниципаль районы Советы аппараты һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.